КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1395

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1132 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1132 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибендә:

5 пунктта «2.2.9.2510-09 нчы санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 18 май, 30 нчы карары (алга таба – Гигиена таләпләре)» сүзләрен «Хезмәт шартларына карата санитария-эпидемиология таләпләре» 2.2.3670-20 нче санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2020 ел, 2 декабрь, 40 нчы карары (алга таба – 40 нчы карар)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Гигиена таләпләренә» сүзләрен «40 нчы карарга» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин